Московская татарская православно-христианская община объединяет московских татар, исповедающих Христа. Община действует при приходе строящегося храма пророка Даниила на Кантемировской г. Москвы.

Богослужение на татарском языке регулярно проходит в храме ап. Фомы на Кантемировской (временном).

тел. храма: 8-926-430-3327

Проезд до ст. м. Кантемировская, выход из последнего вагона (от центра), 7 мин. пешком в сторону реки Чертановка.




# Православный Молитвослов

Издательство храма пророка Даниила на Кантемировской

## на татарском языке

**Православный молитвослов на татарском языке.** М.: Издательство храма пророка Даниила на Кантемировской, 2007. — 32 с.

Православный молитвослов на татарском языке включил в себя основные христианские молитвы и псалмы. Утренние и вечерние молитвы позволят верующему пребывать в молитве к Богу в течение всего дня.

© Макет и оформление издательства
храма пророка Даниила на Кантемировской, 2007

барысын да кичеря кюр. Жазыкларымны кичерер ӧчӧн, ӱземне мяҥге тормошка куяр ӧчӧн айыбламыйчы миҥа арыу Яшерекляреҥнян ӧлӧш алдыр.

## Вечери Твоея…

Эй Алла Улы, бӧгӧн мине Яшерекле ашыҥнан ӧлӧш алырга кабыл ал. Мин яшерегеҥне дошманнарыҥа барыб әйтеб, Сине ӱбеб тотороб биргян Іуда кюк булмам, качтагы талаучы кюк булыб Сиҥа ышаныб әйтямен: эй Ходай, ӱз падшалыгыҥда мине исеҥя ал.

## Да не в суд…

Эй Ходай, шушы арыу Яшерегеҥнян ӧлӧш алыб, хокӧмгя тӧшӧб айыбланасы булмасам ыйы, жаным тянем тӧзялсен эйе.

ХристосъСиңаурыннашыргаирекиткян. Безгя телякче булганың өчөн кӧнӧ-тӧнӧ теляк итеб торасын, теляклярең белян падшалыкны ныклыйсын, Шуңар кюря, эй дяўлятең бар изге Кыз сӧйӧн, Ходай Синең белян диб, Сине ололойбыз.

## Молитвы, читаемые в храме, перед Причастием

*Верую Господи…*

Эй Ходай Іисусъ Христосъ, мин чын кюңелдян ышаныб телем белян айтямен: Син тере Алланын Улы диб, жазыклыларны коткарыр ӧчӧн дӧньягя килгян диб; жазыклылар арасында иң жазыклысы мин. Тагы ышанамын, былар таза Тянең ўзе, арыу Каның ўзе диб. Инде инялямен Сиңа, мине жарлыка; иректян ирексездян, белеб жя белмей, сюз белян жя эш белян кылган жазыкларымны



## Молитвы утренние

Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя. Аминь.

### Молитва мытаря

Эй Алла, мин жазыклыга изгелекле бул.

### Молитва предначинательная

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синең кадерле Таза Анаңнын да,

кюнгелляренде Алланы жөрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар äўлеяляренгнен дя теляклярe какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

Шөкөр Синга, эй Аллабыз, шөкөр Синга.

## Молитва Святому Духу

Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюнелгя чын белем биреўче Тын, кайда булса да бар Син, барын да өлгөрттерясен, äр-төрлө жакшылыкка бай Син, терелек биреўче Син Ўзенг, безгя килеб урыннаш, безнен äр-бер шакшылыгыбызны äрче, жаннарыбызны коткар, Син изгелекле.

## Трисвятое

Святый Алла, Святый Кодрятле, Святый Ўлемсез, безне жарлыка (3 табкыр).



Эй Ходай, ышаныб торганым Син (диб äйтеўенг белян), Жугарыгыны син сыйындырыучынг иттенг шул. Синга жаманнык теймяс, жортонга да ауырыу жакыннашмас. Äр-бер жөрөшөндя сине Ўз пяриштяляреня саклатыр шул. Сине алар кулларына кютяреб барырлар, аягынг ташка сөртөнмяс. Аспидъ, Василискъ дигян жыланнарны жянчерсен, арысланны, аждагыны табтарсын. Минга өмөт тотканы өчөн аны коткарырмын, исемемне белгяне өчөн аны каблаб торормын. Минга тилмерся, аны эшетермен; кайгысында булышырмын; аны аралаб алырмын; аны данналдырырмын. Аны кюб жяшятермен, коткарганымны ангар кюргезермен.

## Блажим Тя вси роди

Эй Алланы тыудырган изге Кыз, без äр-төрлө затлар Сине даннаб торабыз, ич нястягя сыйышырлык төгөл Аллабыз

*Две молитвы, читаемые*
*во время бедствия, при нападении*
*врагов и во всякой напасти*

## 90 псалом

Жугарыгы (Ходай) булышыб торган кеше кюктяге Алланын бӧркяӱе эченя урыннашыр. Ходайга ăйтер: жаклаучым, сыйындырыучым, ышаныб торган Аллам дирер. Сине Ул тотарга жӧрӧӱченен тозагыннан, ăляк сюздян коткарыр шул. Сине жилкясе белян каблаб торор, канатлары асында курыкмый торорсон; Анын чынныгы каблауыч кюк сине жабыб торор. Тӧндяге куркынычтан, кӧндӧз атылыб килгян уктан. Карангыда була торган зыяннан, чирдян, тӧш багытындагы женнян курыкмассын. Сул жагыңда меңняб жыгылырлар, ун жагында ун меңняб кырылырлар, сиңа жакыннашмас та. Син тик кюз салыб кна усалларга кайтарылганны кюрерсен.



Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга ăле дя, ăр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

## Молитва ко Пресвятой Троице

Эй иң Святый ӧч vпостасьле Алла, безне жарлыка; эй Ходай, безне жазыктан тазарт; эй безне тотоб Тороучы, законыңнан жазганыбызны кичер; эй Святый, безгя изгелек кылыб, безнен житешмягян жиребезне тӧзят, Ӱз исемең ӧчӧн.

Эй Ходай жарлыка (3 табкыр).

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга ăле дя, ăр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

## Молитва Господня

Эй кюктяге Атабыз! Данны булыб торсон исемең Синең, килсен падшалыгың Синең, жирдя дя кюктягечя булсын иркең Синең. Бӧгӧн кӧннӧк икмягебезне бир безгя. Бурычларыбызны

кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк. Безне алданырга ирек жибярмя. Жаманнан коткар безне.

Эй Ходай жарлыка (12 табкыр).
Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга äле дя, äр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

Килегез, Падшабыз Аллага башырыйык.
Килегез, Падша Аллабыз Христоска жыгылыб башырыйык.
Килегез, Падша Аллабыз Христоснын Ӱзеня жыгылыб башырыйык.

## 50 псаломъ

Эй Алла, Ӱзенгнен оло изгелегенгнян мине жарлыка, Ӱзенгнен кюбрахименгнян жазыгымны äрчеб бетер. Бигряк мине законсызланыуымнан жыу, жазыгымнан мине тазарт. Законсызланганымны



Синенгисеменгнеданныйбыз, эйышанычылар барыгызда килегез, терелеб торган святый Христоска башырыйык, мына кач белян буган дӧньягя сӧйӧнӧч килгян, Ходайны жалан даннаб, Анын терелеб торганын жырлыйык, кадакланыуны тӱзеб ӱлгяннегге белян ӱлемнен кыуатын бетергян.

## Молитва святого Ефрема Сирина

*(Господи и Владыко живота…)*

Эй мине тере Тотоучы Ходай! Мине жалкаулыкка, ӧмӧтсӧзлӧккя, кӧпӧрлӧккя, бушны сӧйлягргя бирендермя.

Мин мяндянгя шиксез тороулык, жыуашлык, тюземнек, сӧйӧулек бир.

Эй Падша Ходай, минга ӱз жазыкларымны кюрергя, кеше айыбларын кюрмяскя кыуат бир, Син даннаулы гумердян гумергя, аминь.

# МОЛИТВЫ РАЗНЫЕ

## Воскресение Христово…

Христоснын терелеб торганын кюргячен Святый Ходай жазаксыз бер Іисуска башырыйык, эй Христосъ Синеҥ Качыҥа башырабыз, Синеҥ арыу терелеб торганыҥныда даннаб жырлыйбыз: шунын ӧчӧн Син безнен Аллабыз, Синнян башка бӱтянне белмейбез,



тоямын, жазыгым жалан кюз алдымда тора, Мин Синеҥ Ӱзеҥюк жазыкландым, жаман эшне кюз алдыҥда кылдым. Син Ӱз сюзендя туры, хокӧмӧҥдя мине тейешлечя айыбларсын. Мин анамда жаралгандук жазыклы, анам мине жазыклы кӧйӧ тыудырган шул. Син чынны жаратасын шул, белемнегеҥнен айырмачык тӧгӧл жяшереннярен миҥа белдерттеҥ. Миҥа сибкеч белян сибярсен, мин тазарырмын; мине жыуарсын, мин кардан да бигряк агарырмын. Миҥа сӧйӧнӧч, кыуаныч эшеттерерсен, уалган сӧяклярем сӧйӧнӧрляр. Жазыкларымнан жӧзӧҥнӧ бор, законсызланыуларымны кичереб бетер. Эй Алла, мине таза кюҥелле ит, эчемдяге тынымны жаҥартыб арыу ит. Ӱз жӧзӧҥнян мине кыума, Ӱзеҥнен Арыу Тыныҥны миннян алма. Коткарыуыҥ белян мине тагы сӧйӧндӧр, кодрятле Тыныҥ белян мине ныкландыр. Законсызларны жулларыҥа ӧйрятермен, бозок кешеляр Сиҥа

кайтырлар. Эй Алла, мине саклаучы Алла, кан тюгеўдян мине коткар, телем Синеӈ дӧрӧслӧгӧннгне сӧйӧнӧб айтер. Эй Ходай, телемне ачылдыр, ауызым Синеӈ данынгны айтер. Корман теля-сяӈ китерер эйем, тик Син корман жандырыуны телямейсен. Аллага корман кайгылы тын, Алла кайгылы, жыуаш кюнгелне кимсетмяс. Эй Ходай, Ӱз изге-легенгнян Сіонъ тауына жакшылык ит, Іерусалимнен коймалары торгозол-соннар ыйы. Аннары Син дӧрӧслӧк корманын, бюляк кютяреунге, корман жандырыуны кабыл итярсен, аннары корман урнынга бызаулар салырлар.

## Символ веры

1 Ышанамын бер Алла Атага, буган нястялярне Тотоучы диб. Кюкне, жирне, кюреня торганны, кюренмей торганны барысын да Ул булдырган диб. 2 (Жяня



## Когда отходишь ко сну произноси:

Эй Ходай, тынымны Синен кулына табшырамын, Син мине жарлыка, Син мине бахилля, жаныма мянге тере тороу-лык бир. Аминь.

кюрялмый тороучылар Анын жӧзӧннян качсыннар: тӧтӧн таралган кюк таралышыб бетсенняр: утта балауыз эрегян кюк эреб бетсенняр. Алланы сӧйӧӱчеляр дя ӱзляреня Кач билгесе куйыб, эй Ходайнын Терелек биря торган Качы, сӧйӧн, Синҕа кадакланган Ходай Іисусъ Христоснын кыуаты белян женнярне кыуарсыҥ. Ул тамукка тӧшӧб шайтаннарнын кыуатын бетергян, Син Терелек биря торган Качынгны безгя дошманнарны кыуарга биргянеҥ диб айтеӱебездян женняр качсыннар. Эй Ходайнын Терелек биря торган иҥ кадерле Качы, Алланы тыудырган Башкарыучы Кыз белян, бар изгеляр белян бергя гумер буйынчы булышыб тор. Аминь.

**или кратко:**

Эй Ходай, Терелек биря торган кадерле Качыннын кыуатын айлянямдя тотоб, мине ар-торло жаманнан сакла.



ышанамын) бер Ходай Іисусъ Христоска, Алланын жангыз тыуган Улы диб, буган, багытлардан элеке Атадан тыуган, жактыдан чыккан жактыдый, чын Алладан тыуган чын Алла диб, тыуган, жаратылган тӧгӧл, Ӱзе Ата белян бер, барын да Ул булдырган диб. [3] Без кешеляр ӧчӧн, безне коткарыр ӧчӧн Кюктян инҕеб, Святый Тын кыуаты белян Марія Кыздан тяннянеб кеше булган диб. [4] Понтій Пилатъ багытында безнен ӧчӧн Качка кадакланыб, азабланыб, ӱлеб кюмелгян диб. [5] Ӧчӧнчӧ кӧнӧндя ӱлгян жиреннян Алла княгясендягеча терелеб торган диб. [6] Кюккя кютярелеб, Атанын уҥ жагыннан утырган диб. [7] Терелярне, ӱлгяннярне тикшереб айырырга ололок белян тагы килясе, падшалыгы ич тя бетясе тӧгӧл диб. [8] (Жяня ышанамын) Святый Тынга, тере итеӱче Ходай диб, Атадан чыга диб, Ата белян, Ул белян тиҥ табыныулы, тиҥ даннаулы диб, пагамбярляр арткылы Ул сӧйлягян диб.

[9] (Ышанамын) Церковькя, Апостоллар арткылы бөтөн жиргя куйылган бер гня арыу жыйын диб. [10] Чумылдырыу бер диб, жазыкларны кичертя диб әйтямен. [11] Ӱлгянняр терелеб торасы диб. [12] Мянге тормош буласы диб көтямен. Аминь.

## Молитва 1-я, святого Макария Великого

Эй Алла, мин жазыклыны тазарт, мин бер чакта да Синең алдында арыу эш кылмадым шул, мине жаманнан коткар, Синең иркең миндя булсын ыйы, мин ӱземнен тейешсез аузымны айыбламыйчы ачыб, Синең арыу исемеңне, Атаны, Улны, Святый Тынны жырлаб даннасаб ыйы, әле дя, әр-чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 2-я молитва того же святого

Эй кеше сөйөуче Алла, жокодан торгач, Сиңа сыйынамын, Ӱз изгелегең белян



## Окончание молитв

Чыннаб дөрөс тейешле, эй Алланы тыудырган Кыз, Сине кадерляргя, Син мянгегя кадерле, шиксез Таза, Син безнен Аллабызнын Анасы. Херувимнярдян дя кадерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз көйө Сюз Алланы тыудырган, чын Алла Анасы Сине ололойбыз.

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга әле дя, әр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

Эй Ходай жарлыка (3 табкыр).

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синең кадерле Таза Анаңнын да, кюңелляренд я Алланы жөрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар әулеяляреңнен дя телякляре какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

## Молитва Честному Кресту

Безнен белян Алла торсон, Анын дошманнары таралышыб бетсенняр, Аны

тейешсез сюз сӧйляшкян булсам, жя туганымнын жазыгыннан кӧлгян булсам, минем шул жазыкларым санаб бетергесез, жя теляк итяргя жалкауланган булсам, жя бютян тагы исемя килмей торган жаман эшлярем булса, алары бу ӓйткянняремнян дя кюбряктер. Шунгар кюря эй мине Булдырыучы, Башкарыучы, мин ӧмӧтсӧз, тейешсез мяндяҥне жарлыкаб Ӱзеҥ кеше сӧйӧӱче изгегя кюря миҥа ташла, чиш, кичер. Мин жазыклы, азгын, жараусыз, тынычланыб жоклаб тӧннӧ ӱткярсям эйе. Аннары Сиҥа табыныб иҥ кадерле исемеҥне Ата белян, Анын жангыз тыуган Улы белян жырлаб даннасам ыйы ӓле дя, ӓр-чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## Упование мое Отец...

Минем ышанганым Ата, минем сыйынганым Ул, минем жабыучы Святый Тын, эй Святый Ӧчлӧ, шӧкӧр Сиҥа.



Синеҥ эшляреҥне тырышыб Синнян телеймен. Ӓр-бер чакта, ӓр-тӧрлӧ эшкя миҥа кыуат бир, дӧньядя ней усал нястя бар, барысыннан да мине коткар, шайтаннын аздырыуыннан сакла. Мянге Падшалыгыҥа кергез, Син Ӱзен мине жараткан, бар жакшылыкны булдырыб биреӱче Син Ӱзен: минем ышанганым Син Ӱзеҥ. Сиҥа дан китерямен, ӓле дя, ӓр-чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## Молитва 3-я того же святого

Эй Ходай, Син кюб изгелегеҥнян, оло рахимнегеҥнян бу ӱткян тӧннӧн багытын мин мяндяня хатярсез, ичбер зыянсыз ӱткязергя булыштыҥ, инде эй ӓр-нейне Булдырыучы, Башкарыучы Ходай, Ӱзеҥнен чын жактыгнан жактырылган кюҥел белян Синеҥ иркеҥне кыларга мине Ӱзеҥ тейешле ит, ӓле дя, ӓр-чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## Молитвенное призывание святого, имя которого носишь

Эй Алланын ӑўлеясе (исеме), минем ӧчӧн Аллага инял, мин Сиӈа сыйыныб чын кюӈелемнян инялямен: Сине тиз булышыучы, жаным ӧчӧн теляк итеўче диб белеб.

## Песнь Пресвятой Богородице

Алланы Тыудырган Кыз, сӧйӧн, дяўлятеӈ бар Марiя, Ходай Синеӈ белян. Безнен жаннарга Коткарыучыны тыудыргач, Син данны булган катыннар арасыннан, Синнян тыуган да даннаулы.

## Тропарь Кресту

Эй Ходай, калкыӈны сакла, жортоӈа бярякят бир. Дӧрӧс денне ололаб тотоб саклаучыларга дошманнарын жиӈеб басарга кыуат бир, Качыӈ белян сакла тоткан тормошоӈны.



жя белмей кылган жазыкларым, жяштян начарлыкка кюнеккяннектян, оятсызлыктан, ӧмӧтсӧзлӧктян, Синеӈ исемеӈ белян карганган булсам, жя кюӈелем белян исемеӈне курлаган булсам, беряўне-беряўне тиргягян булсам, ачыуланыб ӓляклягян булсам, жя кайгырткан булсам, жя бер-бер нястягя ачыуланган булсам, жя алдаган булсам, жя тейешсез багытта жоклаб жаткан булсам, жя минем катка жарлы килеб аны кабыл алмаган булсам, жя туганымны кайгырткан булсам, жя беряўне айыблаган булсам, жя мактанган булсам, жя олосымакланган булсам, жя ачыуым килеб жарсыган булсам, жя мин теляктя торганда уйым бу дӧньянен начарлыгына ауышкан булса, жя арыулыктан ауышыуны уйлаган булсам, жя артык ашаган булсам, жя артык эчкян булсам, жя тилереб кӧлгян булсам, жя начар эшлярне уйлаб жӧргян булсам, жя кешедя ӓйбят ӓйбер кюреб ангар кюӈелемне салган булсам, жя

Ӱзеӈнен Арыу Евангелиеӈне аӈнаулык жактысы белян жактырт. Жанымны Качыӈны сӧйӧулӧк белян, кюӈелемне таза, изге сюзляреӈ белян, тянемне няпеслярне басылдыра торган азабларыӈ белян, уйымны Ӱзеӈнен жыуашлыгыӈ белян саклаб, тейешле багытта мине Ӱзеӈне даннарга торгоз. Син була башлаган чагы жук, Атаӈ белян, иӈ изге Арыу Тыныӈ белян гумергя даннаулы шул. Аминь.

## Молитва 3-я ко Пресвятому Духу

Эй Ходай, Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюӈелгя чын белем биреӱче Тын, изгелекле кюӈелеӈ белян мин жазыклы мяндяӈне жарлыкаб, мин тейешсез мяндяӈя бӧгӧнгӧ жазыкларымны барын да ташла, кичер, ӓдям кюк мин бӧгӧн жазыкландым, ӓдям кюк кня тӧгӧл, ӓммя терлеклярдян дя начаррак кыйландым, минем иректян, ирексездян, белеб,



## Молитва о живых

Эй Ходай, сакла, жарлыка минем духовный атам *(исеме)*, мине тыудырган атам-анам *(исемняре)*, карендяшляремне *(исемняре)*, башлыкларымны, миӈа жакшылык кылганнарны *(исемняре)*, барлык Христосъ денен дӧрӧс тотоучыларны барысын да сакла.

## Молитва о усопших

Эй Ходай, исеӈя ал ӱлгян мяндяляреӈне: минем атам анамны, тыуганнарымны, миӈа жакшылык кылганнарны (исемняре), барлык православный Христианнарны да, ирекле, ирексез кылган жазыкларын кичереб, аларны Ӱзеӈнен Кюктяге Падшалыгыӈа керт.

## Окончание молитв

Чыннаб дӧрӧс тейешле, эй Алланы тыудырган Кыз, Сине кадерляргя, Син мяӈгегя кадерле, шиксез Таза, Син безнен

Аллабызнын Анасы. Херувимнярдян дя кадерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз көйө Сюз Алланы тыудырган, чын Алла Анасы Сине ололойбыз.

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга әле дя, әр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

Эй Ходай жарлыка (3 табкыр).

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синеӊ кадерле Таза Анаӊнын да, кюӊелляренде Алланы жөрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар әүлеяляреӊнен дя теляклəре какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.



няпеслярдян, буш уйлардан мине коткар. Эй Ата, Ул, Святый Тын, Падшалык, кыуат, ололок Синеке, әле дя, әр-чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## Молитва 2-я, святого Антиоха, ко Господу нашему Иисусу Христу

Эй барын да Тотоучы Алла Сюзе, эй иӊ кадерле Іисусъ Христосъ, Үзеӊнен кюб изгелегеӊ какына мин мяндяӊне ташлама, әммя жалан минем белян була кюр. Эй Үзеӊнен сарыкларыӊны арыу көтөүче Іисусъ, мине жыланнын усаллыгына ирек бирмя, мине шайтан иркеня калдырма, миндя үлем орлого бар шул. Эй без табына торган Алла Ходай, изге Падша Іисусъ Христосъ, Үзеӊнен бетмей торган жактыӊ белян өйрянеүчеляреӊне арыуландырган, Святый Тыныӊ белян мине жоклаган чагында сакла. Эй Ходай, жоклаган урнымда мин жараусыз мяндяӊя котолоу бир. Минем уйларымны

кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк. Безне алданырга ирек жибярмя. Жаманнан коткар безне.

Эй Ходай жарлыка (12 табкыр).

## Молитва 1-я, святого Макария Великого, к Богу Отцу

Эй мянге Алла, эй бар булдырылганнарнын Падшасы, мине бу сагаткя житешергя тейешле кюреўче, бӧгӧн эш белян дя, сюз белян дя, уй белян дя кылган жазыкларымны миӈа кичер. Эй Ходай, минем мескен жанымны да, тянемне дя, танымны да ăр-тӧрлӧ шакшылыгыннан тазарт. Эй Ходай, бу тӧннӧ тыныч жоклаб ўткязергя миӈа булыш, мин жарлы гна урнымнан тороб гумеремнен бар кӧннярендя дя Синеӈ арыу исемеӈне даннасам ыйы. Шулай итеб миӈа карышылык итеўче тянне, тянсез дошманнарны жиӈсям эйе. Эй Ходай, мине шакшыландыра торган жаман



# Молитвы вечерние

Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя. Аминь.

## Молитва мытаря

Эй Алла, мин жазыклыга изгелекле бул.

## Молитва предначинательная

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синеӈ кадерле Таза Анаӈнын да,

кюнгелляряндя Алланы жӧрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар ӓӱлеяляренгнен дя теляклярe какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

Шӧкӧр Синга, эй Аллабыз, шӧкӧр Синга.

## Молитва Святому Духу

Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюнгелгя чын белем биреӱче Тын, кайда булса да бар Син, барын да ӧлгӧрттерясен, ӓр-тӧрлӧ жакшылыкка бай Син, терелек биреӱче Син Ӱзенг, безгя килеб урыннаш, безнен ӓр-бер шакшылыгыбызны ӓрче, жаннарыбызны коткар, Син изгелекле.

## Трисвятое

Святый Алла, Святый Кодрятле, Святый Ӱлемсез, безне жарлыка (3 табкыр).



Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга ӓле дя, ӓр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

## Молитва ко Пресвятой Троице

Эй инг Святый ӧч vпостасьле Алла, безне жарлыка; эй Ходай, безне жазыктан тазарт; эй безне тотоб Тороучы, законынгнан жазганыбызны кичер; эй Святый, безгя изгелек кылыб, безнен житешмягян жиребезне тӧзят, Ӱз исеменг ӧчӧн.

Эй Ходай жарлыка (3 табкыр).

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга ӓле дя, ӓр-чакта да гумердян гумергя, аминь.

## Молитва Господня

Эй кюктяге Атабыз! Данны булыб торсон исеменг Синенг, килсен падшалыгынг Синенг, жирдя дя кюктягечя булсын иркенг Синенг. Бӧгӧн кӧннӧк икмягебезне бир безгя. Бурычларыбызны